**КАРАР**
**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Тымытык авыл җирлеге Советы**

Тымытык авылы №79-128 25 июнь 2019 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль
районы Тымытык авыл җирлеге Генераль планы
(үзгәрешләр кертү) турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 24 статьясы нигезендә, «Россия Федерациясе җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 - ФЗ номерлы Федераль закон», Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге Уставы белән, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Тымытык авыл җирлеге генераль планы проектына (үзгәрешләр кертү) 05.04.2019 ел №10-53/3934 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган уңай бәяләмә нигезендә, 21.12.2018 ел Тымытык авыл җирлеге Генераль планы (үзгәрешләр кертү) проекты буенча ачык тыңлаулар нәтиҗәләре буенча

Тымытык авыл җирлеге Советы карар чыгара**:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге генераль планын (үзгәрешләр кертү) расларга.
2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлегенең генераль планы (үзгәрешләр кертү) турында»2016 елның 21 декабрендәге 44-25 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге адрес буенча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru.урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, экология һәм җир мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис Э.Х. Гыйләҗева